**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» Указына һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне һәм аларга хезмәт күрсәтүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 һәм 24 статьялары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-239 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Дәүләт хезмәткәре элек биләгән вазыйфасыннан дәүләт хезмәте вазыйфаларының югарырак төркеменә караган дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләнгән очракта аңа классны чин өчен оклад күләме, ул били торган вазыйфага караучы вазыйфалар төркеме өчен беренче классны чин бирелгәнгә кадәр, вазыйфаи окладка процентлы ставкалар күләменнән чыгып, өч процент күләмендә түләнә.

Дәүләт хезмәткәре элек биләгән вазыйфасыннан дәүләт хезмәте вазыйфаларының түбәнрәк төркеменә караган дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләнгән һәм аңа элек биләгән вазыйфасы буенча классны чин бирелгән очракта аңа классны чин өчен оклад күләме вазыйфаи окладка процентлы ставкалар күләменнән чыгып, җиде процент күләмендә түләнә.»;

б) 5 пунктның 7 пунктчасы икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә:

«Дәүләт хезмәткәренә еллык түләүле отпуск өлешләп бирелгән очракта еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү отпускның бер өлешен алганда бирелә. Бер тапкыр бирелә торган түләү дәүләт хезмәткәренең еллык түләүле отпуск яисә аның бер өлешен алуга гаризасы нигезендә бирелә.»;

в) 1 нче кушымтаның 5 бүлегендә:

| | | |
|---|---|---|
| « Татарстан Республикасы Хисап палатасы аппараты идарәсе башлыгы | 06-1-2-03 | 3,156 |